**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **20 ноябрь 2021 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенә керүче Әгерҗе авылында 2022 елдаүзарасалым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегендә халык җыены карар бирә:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Әгерҗе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500.00 (биш йөз) сум күләмендә, 1 төркем инвалидлар, укучыларның көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 80 яшьтән өлкән пенсионерлар өчен 400 сум күләмендә, алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

- Әгерҗе авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларга вак таш сатып алу, таш салу, таш җәю, С.Хәким, килешү буенча эш өчен түләү);
- чишмәләр территорияләрен төзекләндерү (күперләрне ремонтлау өчен материаллар сатып алу, урнаштыру);
-җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (ял итү урыннарын төзекләндерү – батут сатып алу);
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Корбан бәйрәме», «Яңа ел " бәйрәм чаралары, спорт чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү»);
- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырып, триммер белән чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, килешү буенча эшләр, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу);
- трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү.

2. Әлеге халык җыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Әгерҗе авылы, Г.Ахметова урамы, 1 йорт адресы буенча, Әгерҗе авылы, С.Хаким урамы, урам чатында, Әгерҗе авылы, Г.Гафиятуллина урамы, 10 йорт белән 23а йорты арасында урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әгерҗе авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Хәсәнов